КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 5 декабрь г.Казань № 1047

Татарстан Республикасыннан читтә татар теле һәм әдәбияты педагогларының татар телен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм итү буенча грантлар бирү турында

Татар телен саклап калу, Россия Федерациясендә татар милли мәдәниятен үстерү һәм популярлаштыру, Татарстан Республикасыннан читтә татар теле һәм әдәбияты педагоглары инициативаларына ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасыннан читтә татар теле һәм әдәбияты педагогларының татар телен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм итү буенча грантлар гамәлгә куярга.

2. Букарарга теркәлгән Татарстан Республикасыннан читтә татар теле һәм әдәбияты педагогларының татар телен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм итү буенча грантлар бирү турындагы нигезләмәне расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 5 декабрь, 1047 нче
карары белән расланды

## Татарстан Республикасыннан читтә татар теле һәм әдәбияты педагогларының татар телен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм итү буенча грантлар бирү турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасыннан читтә татар теле һәм әдәбияты педагогларының татар телен саклау һәм үстерү буенча инициативаларына ярдәм итү буенча грантлар (алга таба – грантлар) бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Грантлар бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 10 сентябрь, 821 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыруга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Нигезләмә нигезендә грантлар бирүгә бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге Нигезләмәдә аннан файдалану максатларында түбәндәге терминнар кулланыла:

грант алырга теләүче – Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында, өстәмә белем бирү оешмаларында «татар теле һәм әдәбияты» предметы буенча яки татар телен өйрәнүгә бәйле өстәмә белем бирү юнәлеше буенча гомуми белем бирү программасын, өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы педагогик хезмәткәр;

грант алучы – грант алу өчен сайлап алу (алга таба – сайлап алу) йомгаклары буенча грант бирү турында карар кабул ителгән грант алырга теләүче;

проект – Татарстан Республикасыннан читтә татар телен саклау һәм үстерү шартларын булдыруга юнәлдерелгән чара.

4. Субсидия бирү максатлары:

Татарстан Республикасыннан читтә татар телен саклау һәм үстерү буенча проект гамәлгә ашыручы татар теле һәм әдәбияты педагоглары инициативаларына ярдәм итү;

Татарстан Республикасыннан читтә татар телен өйрәнүне камилләштерү өчен шартлар тудыру.

5. Ел саен һәрберсе 100 000 (йөз мең) сум күләмендә биш грант бирелә. Грант аны алучыга бер тапкыр бирелә.

6. Грантлар бирү нәтиҗәсе – кимендә бер проект гамәлгә ашыру:

грант бирелгән елның 30 декабренә кадәр кимендә 50 кеше өчен түгәрәкләр, онлайн-курслар, мәдәни-белем бирү чаралары үткәрү;

грант бирелгән елның 30 декабренә кадәр Татарстан Республикасыннан читтә татар телен саклау һәм үстерүгә юнәлдерелгән, кимендә А5 форматында кимендә 20 табак бит яки электрон урнаштыруга эквивалент булган кимендә бер китап, мәкалә яки башка басма чыгару.

Грант бирү нәтиҗәләренә грант бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча ирешелергә тиеш.

7. Грант бирү шартлары:

Министрлык тарафыннан оештырыла торган сайлап алуда җиңү;

проектны гамәлгә ашыру чорында гомуми белем бирү оешмасында, өстәмә белем бирү оешмасында хезмәт педагогик эшчәнлеген башкару.

8. Сайлап алуда катнашуга заявканы (алга таба – заявка) карап тикшерү һәм грант бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү датасына карата грант алырга теләүче туры килергә тиешле таләпләр:

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлегенә контроль турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган физик затлар исемлегендә тормый;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле физик затлар исемлегендә тормый;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмау;

әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый.

9. Сайлап алу критерийлары:

заявка бирү датасына карата грант алырга теләүче тарафыннан кимендә өч ел дәвамында хезмәт педагогик эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

грант алырга теләүченең белем турындагы һәм (яисә) квалификация турындагы документы укытыла торган укыту предметына һәм аның педагогик эшчәнлеге профиленә туры килү;

проект әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында билгеләнгән грант бирү максатларына туры килү.

10. Грант әлеге Тәртиптә билгеләнгән тәртип һәм сроклар нигезендә ел саен уздырыла торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча бирелә.

Министрлык тарафыннан сайлап алу үткәрү турында боерык кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Министрлык «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба тиешенчә – сайлап алу турында боерык, Министрлык сайты) мәгълүмат урнаштыру юлы белән сайлап алу турында игълан итә. Министрлык сайтында урнаштырыла торган мәгълүмати хәбәрдә сайлап алуны үткәрү шартлары һәм сроклары, грант алырга теләүчеләргә карата таләпләр, заявка составында тапшырыла торган документлар исемлеге белән заявка формасы, заявкалар бирү адресы һәм ысулы, шулай ук Министрлык сайтында урнаштырылган сайлап алу турындагы боерыкка сылтама бирелә.

Министрлык конкурс комиссиясе беркетмәсе расланган датадан алып өч эш көне эчендә әлеге беркетмә нигезендә Министрлыкның грант бирү турында йә грант бирүдән баш тарту турында карарны раслау хакында боерыгын Министрлык сайтында бастырып чыгаруны тәэмин итә.

11. Заявкаларны кабул итү сроклары, сайлап алуны үткәрү тәртибе һәм сроклары, заявка формасы, грант алырга теләүченең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык формасы, заявкаларны бәяләү критерийлары, Министрлык һәм грант алучы арасында төзелә торган килешү формасы сайлап алу турында боерык белән раслана.

12. Сайлап алуда катнашу өчен грант алырга теләүчеләр Министрлыкка сайлап алу турында боерык белән расланган форма буенча заявка һәм заявка составында түбәндәге документларны тапшыра:

Россия Федерациясе гражданы паспорты күчермәсе;

эш бирүче яисә эш бирүченең башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган белем һәм (яисә) квалификация турында диплом күчермәсе;

гомуми белем бирү оешмасы, өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесе яисә гомуми белем бирү оешмасының, өстәмә белем бирү оешмасының башка вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе яисә грант алырга теләүченең мәҗбүри пенсия иминияте һәм мәҗбүри социаль иминият системаларында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алынган грант алырга теләүченең хезмәт эшчәнлеге һәм хезмәт стажы турында белешмә;

сайлап алу турында боерык белән расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

сайлап алу турында боерык белән расланган форма буенча проект;

грант алырга теләүченең әлеге Нигезләмәнең 8, 9 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм критерийларга туры килүен раслый торган документлар.

Грант алырга теләүче кәгазь чыганакта заявка формалаштыра һәм аны сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда Министрлыкның урнашу урыны адресы буенча яисә Министрлыкка почта аша тапшыра.

Кәгазь чыганактагы заявка составында тапшырылган документлар андагы исемлеккә кертелергә, тегелгән, номерланган һәм грант алырга теләүче тарафыннан таныкланган булырга тиеш.

Министрлык карары буенча, тиешле техник мөмкинлекләр булганда, заявкалар бирү, Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәү шарты белән, шул исәптән шәхси белешмәләрне саклау өлкәсендә, мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып, электрон рәвештә оештырылырга мөмкин. Заявка электрон рәвештә бирелгән очракта, заявка составында тапшырылган документлар заявкага документларның сканерланган күчермәләре рәвешендә теркәлә.

Сайлап алуга бирелгән заявка һәм заявка составындагы документлар грант алырга теләүчеләргә сайлап алу тәмамланганнан соң кире кайтарылмый.

Грант алырга теләүче заявка составында тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җавап бирә.

13. Министрлыкка кергән заявка һәм аның составында бирелгән документлар урнашу урыны буенча Министрлыкка алар кергән датадан алып бер эш көне эчендә теркәлә. Заявка почта аша җибәрелгән очракта, заявка Министрлык тарафыннан почта бүлегендә алынган көннән алып бер эш көне эчендә теркәлә. Заявка электрон рәвештә бирелгән очракта, Министрлык заявканы Министрлыкның электрон адресына кергән көннән бер эш көне эчендә терки.

Теркәлгән заявкалар Министрлык тарафыннан конкурс комиссиясенә сайлап алу турында боерык белән расланган заявкаларны кабул итү тәмамланган көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

14. Заявканы һәм аның составында тапшырылган документларны карап тикшерү Министрлыкның боерыгы белән составы раслана торган конкурс комиссиясе тарафыннан заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан көннән алып 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Конкурс комиссиясе составына гомуми белем бирү өлкәсендә белгечләр, педагогика, филология, татар теле өлкәсендә галимнәр һәм җәмәгатьчелек вәкилләре кертелә. Конкурс комиссиясен формалаштырганда конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары һәм секретаре билгеләнә. Конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның функцияләрен конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

15. Сайлап алу конкурс комиссиясе тарафыннан заявкаларны әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында расланган сайлап алу критерийлары нигезендә бәяләүне үз эченә ала. Сайлап алу критерийлары буенча бәяләү күрсәткечләре сайлап алу турында боерык белән раслана.

Конкурс комиссиясе карары конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары һәм секретаре тарафыннан кул куелган конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

16. Грант алырга теләүчегә сайлап алуда катнашудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы булмаган комплектта тапшыру), һәм (яисә) документларында бирелгән мәгълүмат дөрес булмау;

грант алырга теләүче әлеге Нигезләмәнең 8 һәм 9 пунктларында билгеләнгән таләпләргә һәм сайлап алу критерийларына туры килмәү;

заявканы һәм (яисә) документларны заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган датадан соң тапшыру.

Грант алырга теләүчегә сайлап алуда катнашырга рөхсәт ителмәгән очракта, Министрлык заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә грант алырга теләүчегә заявкада күрсәтелгән электрон почта адресына, сайлап алуда катнашудан баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, бу хакта хәбәрнамә җибәрә.

17. Әлеге Нигезләмнең 15 пунктында күрсәтелгән сайлап алу йомгаклары буенча конкурс комиссиясе тарафыннан җыйган баллар саны кимү тәртибендә грант алырга теләүчеләрнең рейтинглы исемлеге төзелә. Сайлап алуда җиңүчеләре дип сайлап алу йомгаклары буенча иң күп балл җыйган, рейтинглы исемлектә беренче биш урынны алган грант алырга теләүчеләр таныла. Әгәр грант алырга теләүчеләр бер үк күләмдә балл җыйган булса, алар рейтинглы исемлектә заявка бирү датасы һәм вакыты буенча урнаштырыла.

Грант алырга теләүчеләрнең рейтинглы исемлеге конкурс комиссиясе беркетмәсенең аерылгысыз өлеше булып тора.

Конкурс комиссиясе беркетмәсе Министрлыкка аңа куелган датадан алып биш эш көне эчендә җибәрелә.

Министрлык конкурс комиссиясе беркетмәсе нигезендә грант бирү турында йә грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, ул конкурс комиссиясе беркетмәсе кергән көннән алып биш эш көне эчендә Министрлык боерыгы белән раслана.

Грант алучыга грант бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

грант алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

грант алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

18. Грант, Министрлык тарафыннан грант бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу турында боерык белән расланган форма буенча Министрлык белән грант алучы арасында төзелә торган килешү нигезендә бирелә.

19. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

грант бирү максатлары;

грант күләме;

грантны күчерү сроклары һәм тәртибе;

грант бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

грант бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре һәм аларга ирешү сроклары;

проектны гамәлгә ашыру срогы;

Министрлык тарафыннан грант бирү тәртибен гамәлгә ашыруга, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан тикшерү өлешендә ризалык;

грант түләүне туктату очраклары һәм тәртибе;

грантны кире кайтару очраклары һәм тәртибе;

грантны мәҗбүри түләтү буенча чаралар кабул итү сроклары;

грант бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык;

грант алучының проектны гамәлгә ашыру чорында гомуми белем бирү оешмасында, өстәмә белем бирү оешмасында хезмәт педагогик эшчәнлеген гамәлгә ашыру йөкләмәсе;

грант алучының проект гамәлгә ашырылган чорда аны туктату датасыннан алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча Министрлыкка гомуми белем бирү оешмасында, өстәмә белем бирү оешмасында хезмәт педагогик эшчәнлеген гамәлгә ашыруны туктату турында хәбәр итү йөкләмәсе.

20. Грант алучы тарафыннан проект гамәлгә ашырылган чорда гомуми белем бирү оешмасы, өстәмә белем бирү оешмасы белән хезмәт шартнамәсе өзелгән очракта, грант хезмәт шартнамәсе өзелгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кайтарылырга тиеш.

Грант алучы тарафыннан гомуми белем бирү оешмасы, өстәмә белем бирү оешмасы бетерелүгә бәйле рәвештә гомуми белем бирү оешмасы, өстәмә белем бирү оешмасы белән хезмәт шартнамәсен өзелгән очракта, грант кире кайтарылмый.

21. Грант алучыларга грант бирү Министрлык тарафыннан Россия кредит оешмаларында ачылган грант алучының шәхси счетларына акча күчерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

22. Грант алучылар Министрлыкка килешүдә билгеләнгән форма буенча һәм срок эчендә грант бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

23. Министрлык грант алучыларның грантлар бирү тәртибен, шартларын, шул исәптән грантлар бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

24. Грант алучы, грант биргәндә билгеләнгән тәртип, шартлар бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган очракта, шулай ук грант бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән очракта, Министрлыкның язма таләбен алган көннән 30 календарь көн эчендә грантны тулы күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына ирекле рәвештә кире кайтара.

25. Әлеге Нигезләмәнең 24 пунктында билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджеты кеременә грантны ирекле кайтарудан баш тартылган очракта, Министрлык әлеге акчаны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

26. Грантны максатчан куллануны, аны бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.